**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 декабрь № 935

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» эстрада сәнгатенең ачык республика телевизион яшьләр фестивалендә җиңүчеләргә махсус дәүләт стипендияләре турында» 2006 ел, 14 нче август, 414 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Созвездие – Йолдызлык» эстрада сәнгатенең ачык республика телевизион яшьләр фестивалендә җиңүчеләргә махсус дәүләт стипендияләре турында» 2006 ел, 14 нче август, 414 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы»;

әлеге карар белән расланган «Созвездие – Йолдызлык» эстрада сәнгатенең ачык республика телевизион яшьләр фестивалендә җиңүчеләргә махсус дәүләт стипендияләре түләү тәртибе урындагы нигезләмәдә:

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Махсус стипендияләр кандидатларга билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының чагыштырма сметасында тиешле финанс елына әлеге максатларга күздә тотылган акча чикләрендә түбәндәге номинацияләр буенча бер тапкыр түләнә:

«Вокал соло», 1 нче кече төркем (5 – 7 яшь) – һәрберсе 15,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Вокал соло», 2 нче кече төркем (8 – 11 яшь) – 15,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Вокал соло», урта төркем (12 – 15 яшь) кызлар – һәрберсе 20,0 мең сум күләмендә 4 стипендия;

«Вокал соло», урта төркем (12 – 15 яшь) малайлар – һәрберсе 20,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Вокал соло», өлкән төркем (16 – 21 яшь) – һәрберсе 25,0 мең сум күләмендә 5 стипендия;

«Хореография», кече төркем (5 – 11 яшь) – һәрберсе 30,0 мең сум күләмендә 3 стипендия;

«Хореография», урта төркем (12 – 16 яшь) – һәрберсе 35,0 мең сум күләмендә 3 стипендия;

«Хореография», өлкән төркем (17 – 21 яшь) – 40,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Вокаль ансамбльләр», кече төркем (5 – 11 яшь) – һәрберсе 25,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Вокаль ансамбльләр», урта төркем (12 – 15 яшь) – һәрберсе 30,0 мең сум күләмендә 3 стипендия;

«Вокаль ансамбльләр», өлкән төркем (16 – 21 яшь) – һәрберсе 35,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Конферанс», кече төркем (5 – 9 яшь) – һәрберсе 15,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Конферанс», урта төркем (10 – 15 яшь) – һәрберсе 15,0 мең сум күләмендә 2 стипендия;

«Конферанс», өлкән төркем (16 – 21 яшь) – 20,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Вокал соло» номинациясендә фестиваль Гран-прие (5 – 21 яшь) – 70,0 мең сум күләмендә 1 стипендия;

«Хореография» номинациясендә фестиваль Гран-прие – 80,0 мең сум күләмендә 1 стипендия.

«Хореография» һәм «Вокаль ансамбльләр» номинацияләрендә бирелә торган стипендия күләме тиешле бию коллективында һәм (яки) вокаль коллективта катнашучыларның һәрберсе арасында тигез өлешләргә бүленә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\935.doc